| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2018 Красный Бор авылы № 42-1

Красный Бор авыл җирлеге
территориясендә гражданнарның үзара
салым акчаларын кертү һәм куллану
мәсьәләсе буенча җирле референдум
билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10, 11 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»2018 елның 28 августындагы 40-1 номерлы карары, Красный Бор авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 11 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1.2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

I һәм II нче группа инвалидлар, өлкән кешеләрдән (85 яшькә җиткән), торып укучы студентлар(тиешле документлары булган очракта), Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылучылар, ирекле янгын сүндерү дружинасы әгъзаларыннан, ирекән мәхрүм ителгәннәрдән кала, Красный Бор авыл җирлегендә теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 250 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1.Авыл җирлеге торак пунктларын төзекләндерү:

- Красный Бор авылы урамнарын кардан чистарту;
- агынты канаваларны чистарту һәм карап тоту;
- ташландык, хуҗасыз төзелешләрне сүтү;

2.Янгын сүндерү краннары сатып алу.

3.Торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау;

4.Урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу.

5. Красный Бор һәм Зуево авыллары зиратлары территориясен төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны Красный Бор авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе А.Н. Лазарев